**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию диких кабанов африканской чумой свиней и угрозой ее распространения**

В связи с выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий по ликвидации и предотвращению заболевания африканской чумой свиней, в соответствии со статьей 3[1] Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 28 января 2021 года № 37 **постановляю:**

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию диких кабанов африканской чумой свиней и угрозой ее распространения на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

а) в эпизоотическом очаге:

в пределах территории, используемой федеральным государственным бюджетным учреждением «Национальный парк «Нижняя Кама», в Елабужском районе Республики Татарстан, имеющей географические координаты: 55,731394° северной широты и 51,817500° восточной долготы;

б) в пределах административных границ села Большие Армалы, села Лекарево, села Танайка Елабужского района Республики Татарстан, поселка Пробуждение Нижнекамского района Республики Татарстан;

в) в пределах административных границ Агрызского, Азнакаевского, Альметьевского, Елабужского, Заинского, Кукморского, Мамадышского, Менделеевского, Мензелинского, Муслюмовского, Нижнекамского, Новошешминского, Рыбно-Слободского, Сабинского, Сармановского, Тукаевского, Тюлячинского, Черемшанского, Чистопольского районов Республики Татарстан.

2. На территориях, указанных в пункте 1 настоящего Указа, в течение 180 календарных дней сохраняются следующие ограничения:

запрет на вывоз свиней, продуктов убоя свиней и продуктов их переработки, не прошедших термическую обработку при температуре

не менее 70 °С, обеспечивающую их обеззараживание, за пределы территорий, указанных в подпункте «в» пункта 1 настоящего Указа;

запрет на реализацию свиней на территориях, указанных в подпунктах «б» и «в» пункта 1 настоящего Указа.

Запреты, указанные в абзацах втором и третьем настоящего пункта, не распространяются на хозяйства, отнесенные к компартментам III и IV и исключенные из территорий, неблагополучных по заболеванию диких кабанов африканской чумой свиней и угрозой ее распространения, в соответствии с пунктами 37 и 38 Ветеринарных правил осуществления профилактических, диагностических, ограничительных и иных мероприятий, установления и отмены карантина и иных ограничений, направленных на предотвращение распространения и ликвидацию очагов африканской чумы свиней, утвержденных приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 28 января 2021 года № 37.

3. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 24 декабря 2020 года № УП-867 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию диких кабанов африканской чумой свиней и угрозой ее распространения».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
10 июня 2021 года
№ УП-473

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтү буенча эпизоотиягә каршы һәм профилактика чаралары үтәлү белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 3[1] статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) эпизоотия чыганагында:

төньяк киңлекнең 55,731394 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,817500 градусы географик координатлары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Алабуга районының «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан файдаланыла торган территория чикләрендә;

б) Татарстан Республикасы Алабуга районының Олы Армалы авылы, Лекарево авылы, Танай авылы, Татарстан Республикасы Түбән Кама районының Пробуждение поселогы административ чикләре кысаларында;

в) Татарстан Республикасы Әгерҗе, Азнакай, Әлмәт, Алабуга, Зәй, Кукмара, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай районнары административ чикләре кысаларында.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә 180 календарь көн дәвамында түбәндәге чикләүләр саклана:

дуңгызларны, 70°С югарырак температурада аларны йогышсызландыруны тәэмин итә торган сәнәгать эшкәртүе узмаган дуңгызчылык продукциясен һәм аларны эшкәртүдән алынган продукцияне

әлеге Указның 1 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән территорияләрдән транспортка төяп чыгаруны тыю;

әлеге Указның 1 пункты «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән территорияләрдә дуңгызларны сатуны тыю.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән тыюлар III һәм IV компартментларга караучы һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә расланган Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтүгә юнәлтелгән профилактика, диагностика, чикләү чараларын һәм башка чараларны тормышка ашыру, карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча ветеринария кагыйдәләренең 37 һәм 38 пунктлары нигезендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, иминлексез һәм чир таралу куркынычы булган территорияләрдән чыгарылган хуҗалыкларга кагылмый.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә хайваннар Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2020 елның 24 декабрендәге ПУ-867 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 10 июнь
№ ПУ-473